КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 июль г.Казань № 624

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче; 2019 ел, 30 август, 735 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 31 нче; 2020 ел, 25 февраль, 141 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы, 2020 ел, 10 ноябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 15 июнь, 455 нче; 2021 ел, 19 июль, 587 нче; 2022 ел, 22 февраль, 153 нче; 2022 ел, 21 апрель, 380 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.26 пунктчага «, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турындагы карарларының, дәүләт ихтыяҗлары өчен алынган җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар барлыкка килү, туктатылу яисә күчү турында мәгълүмат бирелгән, формалаштырылган документлар архивының көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образларын җибәрә» сүзләрен өстәргә;

3.3.102[1] пунктчада:

«, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гавами сервитут билгеләү, аны туктату турындагы карарларының, гавами сервитут билгеләү, аны туктату турында мәгълүмат бирелгән, формалаштырылган документлар архивының көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образларын җибәрә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә карата гавами сервитут билгеләү турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерә, үтенечнамәләрне, карап тикшермичә, кире кайтаруны гамәлгә ашыра, сервитут билгеләү турында карар кабул итә һәм килешү төзи, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен сервитут (Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{25}$ статьясындагы 4 пунктында каралган сервитутлардан тыш) билгеләү турындагы килешүләрнең көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образларын җибәрә.»;

4.3 пунктның 4.3.5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«газ бүлү челтәренең саклау зонасы чикләрен билгеләү, үзгәртү, бетерү турында белешмәләр бирелгән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образлар рәвешендә формалаштырылган документлар архивы, шул исәптән мондый зона чикләре урнашу урынының текстлы һәм график тасвирламасы, әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге – XML форматында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гавами сервитут билгеләү, аны туктату турындагы карарларының, гавами сервитут билгеләү, аны туктату турында мәгълүмат бирелгән, формалаштырылган документлар архивының көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образлары – XML форматында;

сервитут (Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{25}$ статьясындагы 4 пунктында каралган сервитутлардан тыш) билгеләү турындагы килешүләрнең көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образлары – PDF форматында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт ихтыяҗлары өчен җирләрне резервлау, җир кишәрлекләрен һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турында карарларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образлары – PDF форматында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм (яисә) анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектын алу турындагы карарлары нигезендә дәүләт ихтыяҗлары өчен алынган җир кишәрлегенә һәм (яисә) анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар барлыкка килү, туктатылу яисә күчү турында мәгълүмат бирелгән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон образлар рәвешендә формалаштырылган документлар архивы – PDF форматында.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин